*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 60**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге ТСТ (тартык+сузык+тартык) иҗек калыбының санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Дөньяда иң кызганыч – эшкә ялкау кеше.* (Мәкаль)

а) 4
ә) 5
б) 6
в) 8

2. Шигъри юллардагы омонимнарның төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Малай йөгерә*
*Өенә табан,*
*Ялтырый табан.* (Н.Гайсин)

а) саф лексик
ә) омоформалар
б) омофоннар
в) омографлар

3. Парлы сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) таш(бака)
ә) бака(яфрагы)
б) ипи(тоз)
в) мүк(җиләге)

4. Җөмләдәге тартым белән төрләнгән исемнәрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Һәр эшнең дә җае бар, ботканың да мае бар*. (Мәкаль).

а) 2
ә) 3
б) 4
в) 1

5. Раслауны белдерә торган кисәкчәне билгеләгез. **(2 балл)**

а) -мени

ә) дөм
б) кына
в) ич

6. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Ялкауның кулы куеныннан чыкмас.* (Мәкаль).
а) ялкауның
ә) кулы
б) куеныннан
в) чыкмас

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

***Бүгенге*** *эшне иртәгә калдырма.* (Мәкаль).
а) вакыт хәле
ә) урын хәле
б) аергыч
в) тәмамлык

8. Җөмләдәге иярчен компонентның мәгънә ягыннан төрен билгеләгез. **(2 балл)**

Кем башлаган, шул бетерергә тиеш. (Мәкаль).
а) иярчен ия җөмлә
ә) иярчен хәбәр җөмлә
б) иярчен тәмамлык җөмлә
в) иярчен аергыч җөмлә

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

Сөйләмнең иң кечкенә әйтелү берәмлеге – ________________ . Сүздәге авазларны ишетелгәнчә язу ______________ принцип дип атала. Язылышлары төрле, әйтелешләре бертөрле булган сүзләр __________________________ дип атала. ____________________ санының саналмышы булмый. Мөнәсәбәтле сүз һәрвакыт ____________җөмләдә килә.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

*В ягодах калины содержится много полезных веществ. Цветущий куст удивляет своей красотой и целебными свойствами. Наши предки пользовались плодами калины. Из зрелых ягод они варили компоты и делали чай. Хозяйки готовили из калины пастилу, пекли пироги.*

2. Мәкальне укыгыз, биремнәрне башкарыгыз.

*Җиреннән аерылган җиде ел елар, иленнән аерылган үлгәнче елар*. (Мәкаль)

2.1. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне языгыз. **(1 балл)**

2.2. Яңгыраулыкта охшашлану күзәтелгән сүзләрне языгыз. **(2 балл)**

2.3. Борын ассимиляциясе күзәтелгән сүзләрне языгыз. **(2 балл)**

2.4. *Елар* фигыленең заманын, зат-сан белән төрләнешен языгыз. **(3 балл)**

2.5. Җөмләнең баш кисәкләрен, компонент чикләрен билгеләгез; җөмләнең билгеләмәсен языгыз. **(5 балл)**

3. Сез мәкальне ничек аңлыйсыз? Шул хакта 10 җөмлә языгыз. **(16 балл)**